Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче
Кече Әшнәк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**КАРАР**

23 ноябрь 2022 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 23 ноябрендә түбәндәге сораулар буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде: “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү системаларын, су кудыру башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистарту һәм Кече Әшнәк авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;
- авыл чикләрендә (Кече Әшнәк авылында) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш китертү өчен транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Кече Әшнәк авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);
- урамнарны яктыртуны җайга салу;
- Кече Әшнәк авылы урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 160 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 111 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 111 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге составына керүче Кече Әшнәк авылында гражданнар җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. Гражданнар җыенына куелган түбәндәге сорауны **кабул ителгән дип расларга**: "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Кече Әшнәк авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан гайре) һәм мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 300 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- су белән тәэмин итү системаларын, су кудыру башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистарту һәм Кече Әшнәк авылында яшәүчеләргә су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын ремонтлау;
- авыл чикләрендә (Кече Әшнәк авылында) җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш сатып алу;
- Кече Әшнәк авылы урамнарын төзекләндерү өчен вак таш китертү өчен транспорт хезмәтләре өчен түләү;
- Кече Әшнәк авылы урамнарының юл йөрү өлешен кышкы чорда карап тоту (урамнарны чистарту);
- урамнарны яктыртуны җайга салу;
- Кече Әшнәк авылы урамнарының читләреннән чүп үләннәре чабу;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорты;Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорты һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы"ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Хөснетдинова Р.Ә.

Олы Әшнәк авыл җирлеге башлыгы Хөснетдинова Р.Ә.